ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

25 март 2026ел № 2870

Күпфатирлы йорт белән идарә итү алымын сайлау турында карар, торак урынны карап тотуга түләү күләмен билгеләү турында карар кабул итмәгән торак урын милекчеләре өчен торак урынны карап тотуга түләү күләмен үзгәртүнең чик индексын билгеләү турында

Россия Федерациясе Торак кодексының 158 статьясының 4 өлеше, Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының «Күпфатирлы йорт белән идарә итү алымын сайлау турында карар, торак урынны карап тотуга түләү күләме билгеләү турында карар кабул итмәгән торак урын милекчеләре өчен торак урынны карап тотуга түләү күләмен билгеләү буенча, шулай ук шундый түләү күләмен үзгәртүнең чик индексларын билгеләү тәртибен билгеләү буенча методик рекомендацияләрне раслау турында» 2018 елның 6 апрелендәге 213/пр номерлы Приказының 3.6, 4.1 пунктлары, шәһәр Уставының 41 статьясындагы 9 өлешнең 4 пункты нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Күпфатирлы йорт белән идарә итү алымын сайлау турында карар, торак урынны карап тотуга түләү күләмен билгеләү турында карар кабул итмәгән торак урын милекчеләре өчен торак урынны карап тотуга түләү күләмен үзгәртүнең чик индексын 2026 елның 1 гыйнварыннан 2026 елның 30 сентябренә кадәр 9,4% күләмендә билгеләргә.

2. Әлеге карарның гамәлдә булуы 2026 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

3. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны «Челнинские известия», «Шәһри Чаллы» вакытлы матбугат басмаларында, Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (https://pravo.tatarstan.ru) рәсми бастырып чыгаруны һәм аны

«Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә https://nabchelny.ru адресы буенча Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитетның шәһәр хуҗалыгы һәм халык яшәешен тәэмин итү идарәсе башлыгы Р.Ф. Вилдановка йөкләргә.

Башкарма комитет Җитәкчесе
вазыйфаларын башкаручы В.Х. Харисов